МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

№60 08.02.2019

Постановление Карар

Күп фатирлы йортта биналарны
яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан
планлаштыруга рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 30.01. 2019 елгы 02-08-02-2019 нчы протестын үтәү йөзеннән һәм 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында”гы 131 нче Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турындагы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 25.11.2010 елгы “Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында”гы 1564нче Карары нигезендә (Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 03.02.2012 елгы “Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 25.11.2010 елгы “Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында”гы 1564нче Карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 69 нчы Карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 10.04.2013 елгы 254 нче карары белән расланган торак биналарны яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты үз көчен югалткан дип табарга.

2. Күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын 1нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan. ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.Ф. Рщхимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
1нче кушымта
08.02.2019 ел № 60

**Күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеге бирүче әлеге административ регламент (алга таба – Регламент) күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәтләр алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба-гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәтләр Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы районы башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтләрне башкаручы – Чистай муниципаль районының "Шәһәр төзелеше хезмәтләре һәм инфраструктураны үстерү" муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба - Учреждение ).

1.3.1. Башкарма комитет урнашкан урын: : ТР, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 126 нчы йорт.

Учреждение урнашкан урын: ТР, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 нче йорт.

Эш графигы: дүшәмбе, сишәмбе - 13.00тән 17.00 сәгатькә кадәр
Чәршәмбе, пәнҗешәмбе - 8.00дән 12.00 сәгатькә кадәр.
Җомга – кабул итүләр булмый
Шимбә, якшәмбе – ял көннәре

Ял итү һәм туклану вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре буенча билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (84342) 5-14-15, 5-15-54.

Алдан язылу кирәкми.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. Муниципаль районның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайты адресы (алга таба –"Интернет" челтәре): (http://chistopol.tatarstan.ru)

1.3.3. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматны алу мөмкинлекләре:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәтләр турындагы визуаль һәм текст мәгълүматларыннан торган мәгълүмати стендлар чаралары буенча;

2) муниципаль районның рәсми сайтындагы «Интернет» челтәре чаралары буенча (http://chistopol.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (Учреждениедә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә –шәхсән яки телефон буенча;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ алымы белән) – почта буенча кәгазьдә, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Учреждение белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарының мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең Җир кодексы 25.10.2001елгы, №136-ФЗы (алга таба – РФ ҖК) (РФ Законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147нче маддә);

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы 29.12.2004 елгы, №190-ФЗы(алга таба – РФ ШтК) (РФ Законнар җыентыгы, 25.12.2006, №52(1нче өлеш), 5498 нче маддә);

Россия Федерациясенең Торак кодексы 29.12.2004 елгы, 188нче-ФЗы (алга таба –РФ ТК) (РФ Законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1(1нче өлеш), 14 нче маддә);

17.11.1995 елгы “Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында”гы 169 нчы номерлы Федераль закон ( алга таба -169нчы номерлы Федераль закон) (РФның законнар җыентыгы, 20.11.1995, № 47, 4473нче маддә).

06.10.2003 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче номерлы Федераль закон ( алга таба -131нче номерлы Федераль закон) (РФның законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 нче маддә).

27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон ( алга таба - 210нчы номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 нчы маддә);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.04.2005 елда кабул ителгән “Күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру турында гариза формасын һәм күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру килешүе турында карар кабул итүне раслаучы документ формасын

раслау турында”гы 266 нчы карары ( алга таба - 266 нчы карар) (РФның законнар җыентыгы, 09.05.2005, №19, 1812 нче маддә).

Татарстан Республикасының 28.07.2004 елгы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45нче номерлы законы ( Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45 нче номерлы ТР законы);

Чистай муниципаль районы Советының 14.12. 2005 елгы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Чистай муниципаль районы Советы Карары белән расланган Чистай муниципаль районы башкарма комитеты турындагы 16.05.2012 елгы17/4нче Нигезләмә белән (алга таба – БК турындагы нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 21.03.2006 елгы 106-р нчы номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән (алга таба – Кагыйдә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 12.02.2013 елгы 73нче карары белән расланган Чистай муниципаль районының “Шәһәр төзелешен көйләү һәм инфраструктура үсеше” муниципаль бюджет учреждениесе уставы белән (алга таба – Учреждение турында устав)

1.5. Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы сорау дип аңлашыла (27.07.2010 елгы 210 нчы Федераль законның 2 нче пунктының 2 нче маддәсе).

Гариза стандарт бланкта тутырыла.

1.6 Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

- күп фатирлы йортта биналарны яңадан планлаштыру - күп фатирлы йорттагы биналарның техник паспортына үзгәрешләр кертүне таләп итүче күп фатирлы йорттагы биналарның конфигурациясен үзгәртү;
- күп фатирлы йортта биналарны яңадан төзү - күп фатирлы йорттагы биналарның техник паспортына үзгәрешләр кертүне таләп итүче инженерлык челтәрен, санитар-техник, электрик яки башка җиһазларны урнаштыру, алмаштыру яки күчерү;
-торак биналар төрләре: фатир, фатирның бер өлеше, бүлмә, торак йорт, торак йортның бер өлеше.

## 2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандарты

| **Муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге** | **Стандартка таләпләр эчтәлеге** | **Хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт** |
|---|---|---|
| 2.1 Муниципаль хезмәтләр исемлеге. | Күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү | РФ ТК 25-29нчы нчы маддәләр |
| 2.2. Башкарма властьның турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органы исеме | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты | БК турында Нигезләмә |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзүне һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү яки баш тарту турындагы карар (2нче Кушымта) | РФ ТКның 26 нчы маддәсенең 5нче пункты |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми срогы:<br>гаризаны теркәгән вакыттан алып 10 эш көне | ТКның 26 нчы маддәсенең 4 нче пункты |
| 2.5 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәт, аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә тиеш | 1) Россия Федерациясе Хөкүмәте башкарма властеның вәкаләтле федераль органы тарафыннан расланган форма буенча яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру турындагы гариза;<br>2) күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы биналарга хокукны билгеләүче документлар (төп нөсхәләр яки нотариаль тәртиптә расланган күчермәләр);<br>3) билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән күп фатирлы йорттагы бинаны яңартып төзү һәм (яки) яңартып төзелгәнне яңадан планлаштыру һәм (яки) яңадан | ТКның 26 нчы маддәсенең 2 нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | планлаштыру проекты, әгәр күп фатирлы йортта уртак мөлкәт өлешен әлеге бинага кушмыйча гына күп фатирлы йорттагы бинаны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру мөмкин булмаса, шулай ук күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының барысының да күп фатирлы йорттагы биналарны шундый яңартып төзүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга ризалашуы турында гомуми җыелыш беркетмәсе, әлеге Кодексның 40 нчы маддәсенең 2 нче өлеше белән каралган;<br>4) күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы бинаның техник паспорты;<br>5) социаль найм килешүе нигезендә күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы бинаны алып торучы яллаучы гаиләнең барлык әгъзаларының ( шул исәптән яллаучы гаиләнең вакытлыча яшәмәүче әгъзалары да) да язма формадагы ризалыгы (әгәр социаль найм килешүе нигезендә күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы бинаны алып торучы әлеге пункт белән каралган документларны бирүгә гариза бирүче булып вәкаләтле наймга бирүче торса);<br>6) күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру үткәрүне рөхсәт итү турында архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен (әгәр шундый йорт яки бина архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәле булып торса) саклау буенча орган нәтиҗәсе. | |
| 2.6 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, | Ведомствоара үзараэлемтә кысаларында ясала:<br>1) күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы биналарга хокукны билгеләүче документлар, әгәр аңа хокук күчемсез милекнең Бердәм | |

| | | |
|---|---|---|
| алар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында һәм аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә хаклы. | дәүләт реестрында теркәлгән булса;<br>2) күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы бинаның техник паспорты;<br>3) күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру үткәрүне рөхсәт итү турында архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен (әгәр шундый йорт яки бина архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәле булып торса) саклау буенча орган нәтиҗәсе. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актлар белән каралган очракларда килештерү кирәк булган дәүләт оганнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма власть органы тарафыннан гамәлгә ашырыла | Янгын һәм санитар-эпидемиологик органнар белән килештерү ( законда билгеләнгән тәртиптә) . | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1)Документларны тиешле зат бирмәсә;<br>2)Тапшырылган документларның әлеге регламентның 2.5 нче пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә тәңгәл килмәве;<br>3)Гаризада һәм гаризага беркетелгән документларда сөйләшенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген аңлату мөмкинлеге бирмәүче җитди бозулар;<br>4)Документларны тиешле булмаган органга тапшыру. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яисә баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен сәбәпләр:<br>1) әлеге Кодексның 26нчы маддәсенең 2 нче өлеше белән билгеләнгән документларны тапшырмау, әлеге Кодексның 26нчы маддәсенең 2.1 нче өлешен исәпкә алып, | РФ Торак кодексы, 27нче маддәнең 1нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | аларны тапшыру буенча вазифа гариза бирүчегә йөкләнгән.<br>2) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;<br>3) күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру проекты закон таләпләренә тәңгәл килми. | |
| 2.10 Муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе | Муниципаль хезмәт бушлай нигездә күрсәтелә<br>. | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе, шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны үз эченә алып | Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12 Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны биргән һәм шундый хезмәт нәтиҗәсен алган вакытта чиратта торуның максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | Әлеге регламент белән билгеләнгән |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соравын теркәү срогы | Гариза кергәннән соң бер көн дәвамында | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Гариза Учреждениегә кәгазьдә тапшырыла.<br>Эш урыны сорауны рәсмиләштерү өчен өстәл һәм урындыклар белән, сорауны тутыру үрнәкләре һәм хезмәт алу өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат | Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | стендлары белән җиһазландырылган. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Административ регламентны бозуга прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булу.<br>Муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) күрсәткәндә консультацияне, документларны кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече гамәлгә ашыра. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада бирү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләр алу тәртибе турындагы консультацияне Интернет-кабул итү аша электрон формада яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br>Әгәр закон тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең ( функцияләрнең) Бердәм порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүче белән консультация үткәрү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнеэ эзлеклелек блок-схемасы 3нче кушымтада китерелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Учреждениегә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Учреждение белгече гариза бирүче белән консультация үткәрә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен башка сораулар буенча һәм әгәр кирәк булса гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән урнаштырылучы процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1.Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы кеше аша муниципаль хезмәт күрсәтүләрен сорап язмача гариза бирә һәм Учреждениегә әлеге Регламентның 2.5 нче пункты нигезендә документлар тапшыра.

Электрон формада муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза Учреждениегә электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Учреждениенең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә ( ышаныч кәгазе буенча булса);

әлеге Регламентның 2.5нче пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка төзәтүләр булмаска тиеш).

Дәгъвалар булмаган очракта Учреждение белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә документларны кабул итү тамгасы, бирелгән керүче номерны, муниципаль хезмәт күрсәтү көнен һәм вакытын күрсәтеп тапшырылган документларның исемлеге күчермәсен тапшыра;

гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр булган очракта Учреждениенең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече гариза бирүчегә гариза теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрне язма рәвештә аңлатып тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән гаризаны кабул итү һәм теркәү яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Учреждениегә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4.Ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Учреждение белгече хезмәт күрсәтү турындагы сорауларны электрон формада ведомствоара үзара электрон система чаралары буенча җибәрә:

Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милеккә һәм аның белән килешүләргә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем алырлык белешмә) өземтә;

күп фатирлы йорттагы яңартып төзелүче һәм (яки) яңадан планлаштырылучы бинаның техник паспорты;

күп фатирлы йортта биналарны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру үткәрүне рөхсәт итү турында архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклау буенча орган нәтиҗәсе, әгәр шундый йорт яки бина архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәле булып торса,бинага хокукны раслаучы документлар.

Әлеге пункт нигезендә урнаштырыла торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: власть органнарына җибәрелгән сораулар.

3.4.2. Мәгълүматлар куючы белгечләр ведомствоара үзара электрон система аша кергән сораулар нигезендә соратыла торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында белдерү).

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар ведомствоара сорауның документ яки мәгълүмат бирүче органга яки оешмага керү көненнән алып биш көн дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр Федераль законнар, Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең хокукый актлары тарафыннан ведомствоара сорауга җавап әзерләү һәм җибәрү сроклары билгеләнмәгән һәм федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән кабул ителмәгән булса.

Процедура нәтиҗәсе: Учреждениегә җибәрелгән документлар (белешмә) яисә кире кагу турында белдерү.

3.5 Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Учреждение белгече белешмәләр нигезендә башкара:

рөхсәт бирү турында яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

рөхсәт бирү проекты ( әгәр рөхсәт бирү турында карар кабул ителсә) яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат проекты (рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителсә) әзерли;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү процедурасын гамәлгә ашыра;

рөхсәт бирү проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат проектын башкарма комитет җитәкчесенә (аның вәкаләтле затына) имза куюга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар сорауга җавап кергән көннән соң ике көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкарма комитет җитәкчесенә (аның вәкаләтле затына) имза куюга җибәрелгән проектлар.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (аның вәкаләтле заты) рөхсәт бирү турында боерыкны раслый, рөхсәткә имза куя һәм аны башкарма комитет мөһере белән раслый яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны раслый һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хатка имза куя. Имза куелган документлар башкарма комитетның гомуми бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар проектлар раслауга кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: рөхсәт бирү турында расланган боерык һәм имза куелган рөхсәтнамә яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында расланган боерык һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында имза куелган хат.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру

3.6.1. Башкарма комитет белгече:

теркәүләр журналында рөхсәт бирү турындагы ( рөхсәт бирүдән баш тарту турында) карарны терки;

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар Башкарма комитет җитәкчесе документларга кул куйган көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр.

3.6.2. Учреждение белгече:

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән рөхсәтнең яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хатны тапшыру көнен һәм вакытын хәбәр итә;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән рөхсәтне яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хатны (баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп) бирелгән рөхсәтләр журналында кул куйдырып бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар тормышка ашырыла:

рөхсәт яки баш тарту турында хат бирү - гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә 15 минут эчендә:

баш тарту турындагы хатны почта аша җибәрү - процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн дәвамында, әлеге Регламентның 3.5.3нче пунктында каралганча.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәт яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат.

3.7.Муниципаль хезмәтне МФҮ аша күрсәтү.

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен МФҮкә мөрәҗәгать итәргә хаклы.

3.7.2. МФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү МФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга МФҮтән документлар кергәндә процедуралар әлеге регламентның 3.3-3.5 пунктлары нигезендә тормышка ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе МФҮгә җибәрелә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм контрольдә тоту алымы

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә тикшерү үткәрүне, җирле үзидарә органының вазифаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне күзәтү өчен контроль алымнары булып торалар:

1) муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Проектларны визалау тикшерү нәтиҗәсе булып тора;

2) эш производстволарын алып баруга билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр уздыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының яртыеллык яки берьеллык эш планнары нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең төгәл бер мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндәге гамәлләрне кылуга контрольлек итү максатында башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча билгеләнгән административ процедуралар эшенең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольне башкарма комитет

җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары (муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен җаваплы), шулай ук Учреждениенең инфраструктура үсеше белгечләре гамәлгә ашыра

4.3. Агымдагы контрольне тормышка ашыручы вазифаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур подразделениеләре турындагы нигезләмәләре һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җавапка тартыла.

